**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2020елның10 ноябре 2547номер

# КАРАР

## Столбище авыл җирлегенең, Усад авылындагы җир кишәрлекләрен ызанлау проектын эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, план структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләре урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында карар бирәм:

1. «Компроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә Лаеш муниципаль районында, кадастр номерлары 16:24:150304:448, 16:24 304:449, 16:24:150304:30449, 16:24:150304:475 булган Столбище авыл җирлеге, Усад авылы җир кишәрлекләрендә территорияне ызанлау проектын әзерләргә.

2. 2020 ел эчендә Лаеш муниципаль районында, Столбище авыл җирлеге Усад авылында күрсәтелгән территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү срогын билгеләргә.

3. Территорияне планлаштыру һәм ызанлау документларын әзерләү һәм тоту тәртибе турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан эш көннәрендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Лаеш шәһәре, Чернышевский ур., 23 й..

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча һәм«Кама ягы» ( «Камская новь») район газетасында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.А. Новиков